**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 28 » июнь 2019 ел** **№ 175**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 08.05.2018 ел №100 карарына үзгәрешләр кертү турында (25.07.2018 №151, 18.10.2018 №306, 28.12.2018 №366, 03.049 №84 карарлар редакциясендә)

29.07.2017 ел 217-ФЗ номерлы «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны үтәү йөзеннән **карар бирәм:**

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 08.05.2018 ел №100 карарына (25.07.2018 №151, 18.10.2018 №306, 28.12.2018 №366, 03.049 №84 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль милектәге гражданнарга дача хуҗалыгын алып бару өчен җир кишәрлеге (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты»ның №35 кушымтасын төшереп калдырырга.

2. Түбәндәге үзгәрешләрне №51, 54 кушымталарга кертергә:

2.1. исемендә һәм алга таба текст буенча «гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек, дача коммерциячел булмаган берләшмәсе әгъзасы булган гражданга җир кишәрлеген түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» №51 кушымта тексты буенча тиешле килешләрдә «дачный» сүзләрен төшереп калдырырга.

2.2. исемендә һәм алга табатекст буенча «гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек, дача коммерциячел булмаган берләшмәсенә гомуми файдалану милкенә керә торган җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» №54 кушымта тексты буенча тиешле килешләрдә «дача» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Бу карар 2010 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов